# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында
гражданнардан үзара салым кертү турында

**18.03.2024 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге башлыгының 07.03.2024 елгы 4 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 25.11.2023 елгы 1 номерлы, “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” 25.11.2023 елгы 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш авылы гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 25.11.2023 елгы №1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында 2024 елда гражданнардан үзара салым кертү турында» 25.11.2023 елгы № 2 гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Тырыш авылындагы юлларны кардан чистартучы тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәте өчен, кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү; вак ташны сатып алу, ташу, Октябрьнең 70 еллыгы урамына вак ташны җәю (эшкә килешү буенча түләү)).».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Илбәк авыл җирлеге мәгълүмати стендында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru),Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге Башлыгы Р.К.Галимҗанова